РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

Тел.:8(84364)2-63-02, факс:8(84364)2-63-04,e-mail:Kukmor.Kuk@tatar.ru,www:kukmor.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«10» декабрь, 2025 ел №100

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендә йорт хайваннарын йөртү урыннарын билгеләү турында

«Хайваннар белән эш итү җаваплылыгы турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын тотуга, шул исәптән аларны йөртүгә карата өстәмә таләпләрне раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 11 августындагы 971 номерлы карары, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы башкарма комитеты Уставы нигезендә, йорт хайваннарын йөртү өчен гражданнарның, хайваннарның иминлеген, физик һәм юридик затларның мөлкәтен саклап калуны тәэмин итә торган шартлар тудыру максатларында, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты карар бирә:

1. Йорт хайваннарын йөртү өчен рөхсәт ителгән урын (урыннар) итеп түбәндәгеләрне билгеләргә: 1) Ленин урамы, 34 нче йорт – спорт мәйданчыгы артындагы бушлык (якынча координаталар 56.184532, 50,895280); 2) Ленин урамы – ДОСААФ автодромы (якынча координаталар 56.185010, 50.929384); 3) Гагарин ур. – «Туеш зираты» артындагы мәйданчык (якынча координаталар 56.180917, 50.896726) 4) Май ур. – «Родничок» бакчачылык коммерцияле булмаган ширкәте янындагы мәйданчык (якынча координаталар 56.192452, 50.875800).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресында, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан

Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә йөкләргә.

Җитәкче Андреев В.Н.